СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

29.12.2016 — № 27-110

с. Набережные Моркваши

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваши авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты турында**

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына таянып, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 19, 97-99 статьялары белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2007 елның 25 июнендәге 19-98 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе белән,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карар проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә (№1 кушымта).

2. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча киләсе составта кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

– эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов;

–эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең башкарма комитеты секретаре Ч.Р.Сафиуллина;

Эшче төркем әгъзалары:

- Прохорова Ильмира Ринат кызы - Яр буе Морквашы авыл китапханәсе мөдире;

- Толстова Елена Владимировна-Яр буе Морквашы ОПС начальнигы;

– Самойленко Ирина Николаевна - Яр буе Морквашы мәдәният йорты директоры;

3. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы Карары проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (№2 Кушымта).

4. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (№3 нче кушымта).

5. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлауларны 10 нчы март көнне Яр буе Морквашы мәдәният йортында 10.00 сәгатьтә Яр буе Морквашы авылы, Красавин урамы, 6 нчы йорт адресы буенча уздырырга.

6. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______________И.Х.Гаязов

Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Советының 2016 елның 29
декабрендәге 27-110 номерлы
карарына

1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. Уставның 7.1 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

13) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра»;

2. Уставның 48 статьясындагы 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« - "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра»;

Совет рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ______________И.Х.Гаязов

Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Советының 2016 елның 29
декабрендәге 27-110 номерлы
карарына

2нче кушымта

ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ "ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА" ГЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ.

1. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы Карары проектына тәкъдимнәр, авторның яшәү урыны турында белешмәләрне күрсәтеп, 2017 нче елның 9 нчы мартына кадәр язмача кертелә. Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422594, Яр буе Морквашы авылы, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы эшче төркем секретаре Ч. Р. Сафиуллина, авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында көн саен 8.00 дән 16.00 гә кадәр, шимбә көнне 8.00 дән 12.00 гә кадәр. Белешмәләр өчен телефон: 31-6-47.

Совет рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ______________И.Х.Гаязов

Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Советының 2016 елның 29
декабрендәге 27-110 номерлы
карарына

3 нче кушымта

ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ»ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА " ГЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Халык алдындагы тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422594, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Яр буе Моркваши авылы, Красавин ур., 40 йорт. Югары Ослан муниципаль районының Моркваш авыл җирлеге советына Гаязов И.Х. шәхсән яисә почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» тамгасы белән).

2. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советына язмача гаризалар тапшырган авыл халкы үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнаша.

3. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган халкы катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минуттан башлана.

5. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументлау өчен чакырыла.

6. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

7. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

Совет рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______________И.Х.Гаязов